ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2023 г. с.Ямбулатово № 2

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяры авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Уставы статьясына ярашлы рәвештә,

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяры авылында 2023 елның 19 ноябренә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар арасында халык җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: “Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяры авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 8000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

- Казыльяры авылына юлны төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Казыльяры авылы, Мәктәп урамы, 28 йорт адресы буенча 10.00 сәгатьтә гражданнар җыенын уздырырга.
4. Ямбулат авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы урынбасары М.Н.Ахметзянов